**ГЛАВА СРЕДНЕКАМЫШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**УРТА КАМЫШЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Урта Камышлы ав. **КАРАР**

**«03» ноябрь 2022 ел** **№ 3**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы җирлегенең Абляскино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Урта Камышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2022 елның 17 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Абляскино авылы, Пушкин урамы, 10нчыБ йорты адресы буенча урнашкан кибет бинасында Татарстан Республикасы, Нурлат районы Урта Камышлы авыл җирлеге Абляскино торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Пушкин урамы 1-43нче йортларда яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2022 елның 17 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Абляскино авылы, Пушкин урамы, 10нчыБ йорты адресы буенча урнашкан кибет бинасында Татарстан Республикасы, Нурлат районы Урта Камышлы авыл җирлеге Абляскино торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Лермонтов урамы 1-40нчы йортларда яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын уздыру өчен Абляскино авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге Абляскино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 1000 (мең сум) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- Су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү;
- Абляскино торак пункты чикләрендә авыл эчендәге юлларны төзекләндерү

.

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Абляскино авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы В.П. Вафина